*Ачык тәрбия сәгате. 7 сыйныфлар өчен.*

***Тема:*** **Социаль нормалар арасында хокук нормалары яки яшүсмер үз хокукларыңны беләсеңме?**

Сыйныф җитәкчесе: Садриев Равил мөхтәр улы.

**Максат: 1) Укучыларның башлангыч хокукый белемнәрен киңәйтү;**

**2)Үз фикереңне курыкмый һәм ачык итеп әйтә белү күнекмәләрен үстерү;**

**3)Милли йолаларыбызга, гореф-гадәтләребезгә карата ихтирам тәрбияләү.**

**Норма дигән сүзне ничек аңлыйсыз?**

***Рөхсәт ителгән чик, эшләргә яраган һәм ярамаган әйберләрне аеру.***

**Социаль, социум дигән сүз нәрсәне аңлата?**

***Кешеләр төркеме, җәмәгатьчелек, кешеләрнең үзара мөнәсәбәте.***

***Нәрсәләр ул социаль нормалар ?***

***Җәмгыятьә урнашкан, кешеләр үзара мөнәсәбәткә кергәндә үтәлергә тиешле кагыйдәләр.***


Гореф - гадәтләр
Хокук право
Йолалар
Социаль нормалар
Дини
Әхлакый мораль
Зәукый эстетик

# -*Ни өчен законнарны үтәргә кирәк?*

**Видеоролик карау**

***Кеше хокукы ул  - нәрсә дә булса эшләү, билгеле бер гамәлләр кылу, нәрсәгә дә булса ияру мөмкинлеге.***

***Баланың гражданлык (шәхси) хокуклары :***

-яшәүгә хокук;

-үзенең әти-әнисен белергә хокук;

-хат язышу, дуслар сайлау, телефоннан аралашу һ.б.

-торак кагылгысызлыгы.

***Баланың социаль-икътисади һәм мәдәни хокуклары :***

**-хезмәткә хокук;**
**-һөнәрне ирекле сайлауга хокук;**
**-ял итүгә хокук;**
**-социаль тәэмин ителүгә хокук (“Мәктәпкә җыенырга булыш” акциясе, аз керемле гаиләләргә ярдәм);**
**-белем алуга хокук (бушлай, урта тулы гомуми белем алу);**
**-иҗат иреге (төрле шигырьләр, әкиятләр иҗат итеп газета-журналларда бастырту) ;**
**-мәдәни тормышта катнашу хокукы (“Йолдызлык”, “Кинофестиваль”);**
**-мәдәни учреждениеләрдән файдалану хокукы (клуб, укучылар йорты, *гитара түгәрәге* спорт мәктәбе *көрәш*)**

***Әгәр хокук саклау органнары хезмәткәрләре тарафыннан тоткарлансаң?***

**-Балигъ булмаган үсмерне 72 сәгатькә кадәр тоткарлау рөхсәт ителә;**

**-ни булуы хакында шунда ук әти-әниеңә, туганнарыңа хәбәр итәргә кирәк;**

**-тоткарланган вакытта ук адвокат чакырырга мөмкин;**

**-балигъ булмаганнар үзләренең законлы вәкилләре (әти-әнисе һ.б.) булганда гына аңлатма бирә, шуңа алар килеп җиткәнче дәшмәскә һәм үзләре турындагы мәгълүматлардан (фамилия, исем, атасының исеме, яшәү урыны) тыш берни дә сөйләмәскә була;**

*Әгәр хокук саклау органнары хезмәткәрләре тарафыннан тоткарлансаң?*

**-кулга алганда шәхси тентү булырга мөмкин, ул чакта чит кешеләр – пүнәтәйләр катнашырга тиеш. Бу вакытта беркетмә төзелә;**

**-тутырылмаган беркетмәгә кул куярга ярамый, соңрак аңа дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматлар язарга мөмкиннәр;**

**-"...беркем дә үзенә каршы, тормыш иптәшенә һәм якын туганнарына каршы таныкларга бурычлы түгел..."** ***(РФ Конституциясенең 51 нче маддәсе).***

# Укучылар үтәргә тиешле кагыйдәләр һәм аларның бурычлары.

***-Тиешле вакытта мәктәпкә килү һәм китү, мәктәпкә чиста кием белән керү;***

***-Башка авылдан булганда мәктәп автобусыннан гына файдалану;***

***-Дәрескә соңга калмыйча керү, укытучы рөхсәтеннән башка гамәлләр кылмау***

***-Дәрестә тәртипле булу, укытучының сөйләгәнен игътибар белән тыңлау;***

***-Тәнәфестә коридорда чабып йөрмәскә, мәктәп милкенә сакчыл карарга;***

***-Ашханәдә сөйләшеп ашамаска, савыт-сабаны илтеп куярга;***

***-Дәреслекләрне саклап тотарга, ертылганын ябыштырырга;***

***-Раздевалкада тышкы һәм эчке аяк киемнәрен бер урынга гына куеп йөрергә;***

***-Сәбәпсез дәрес калдырмаска, авырган очракта сыйныф җитәкчесенә хәбәр бирергә;***

# Укучылар үтәргә тиешле кагыйдәләр һәм аларның бурычлары.

***-Мәктәп бакчасында һәм җыештыру өмәләрендә эш кораллары белән сак эш итәргә, очлы предметларны кешегә каратмаска, уйнамаска;***
***-Походларга шырпылар тыгып йөрмәскә, учак якмаска;***
***-Караучысыз калган өлкәннәргә ярдәм итәргә;***
***-Укытучылар һәм өлкәннәр белән исәнләшергә;***
***-Әти-әнигә, укытучыларга һәм башка үзеңнән өлкәнрәк кешеләргә ихтирамлы булырга;***
***-Үзеңнән кечерәкләргә игътибарлы булырга, яхшы яктан үрнәк күрсәтергә һәм кирәк вакытта ярдәм кулын сузарга;***
***-Мәдәни һәйкәлләрне һәм туган як табигатен кулдан килгәнчә сакларга.***

***-Димәк, укучылар, хокуклардан файдалану белән беррәттән бурычларны да үтәргә кирәк!***

***Игътибарыгыз өчен рәхмәт!***